**Рус телендә урта гомуми белем бирү мәктәбенең рус төркемендә укучылар өчен татар теленнән үткәрелә торган олимпиаданың мәктәп туры биремнәрененең җаваплары**
**2021/2022 уку елы, 10 нчы сыйныф**

*Максимальный балл –103 б.*

1. **Прочитай текст, назови (2 б.) допиши пропущенные окончания (по 1б.=8 б.)**

Кулыма икмәк алганда, еш кына сугыш еллары исемә төшә.

Мин 1945 нче елның август башларЫНДА күргән бер күренешне оныта алмыйм. Без, бер группа солдат һәм сержантлар, туган илГӘ кайтып бара идек. Һәркайда җимереклек. Авылларның исемнәре топографик картаДА гына калган.

Шулай кайта торгач, безНЕҢ эшелон кечкенә генә станциягә килеп туктады. Төшәргә команда булмаганга күрә, без ачык ишекТӘН генә тирә-якны күзәтәбез. Шулвакыт безнең вагон янынА 7-8 яшьләрдәге бик ябык малай килеп басты. Без бер сүз әйтмичә генә малайНЫ күзәтәбез. Аның көчсез тавыш белән “ Абыйлар, ипиегез юкмы, ипи бирегезче”, - дип соравыННАН без югалып калдык.

Малай без биргән икмәкне ничек алуын мин беркайчан да оныта алмадым. Табынга утырган саен, икмәк сораган малай искә төшә. Менә бит ул каһәр суккан сугыш!...

**и ответь на следующие вопросы (по 2 б. =10 б.):**

1) Эшелон сугыштан туган илгә кайта.
2) Текстта сугыш беткән чор сурәтләнә.
3) Чөнки аларны яндырганнар, җимергәннәр, юкка чыгарганнар.
4) Маланың ипи соравы һәм алуы.
5) Менә бит ул каһәр суккан сугыш!...

**Итого: 20 б.**

**2.Найди и напиши синонимы прилагательных** (по 2 б., макс. б. -10)

Атаклы , **танылган, данлыклы;**
чибәр , **матур, гүзәл**;
тату, **дус** ;

әйбәт, **яхшы**;
таза, **юан**.

3. **Образуй с помощью аффиксов новые слова (макс. б. -5).**
 Юл + чы = юлчы,юллы, юлсыз, юлдаш, юллый.

4. **Составь предложения (по 2 б., макс.б. – 8)**
   1) Тәмамлагач, табиб, мин, булырга, мәктәпне, телим.
   2) Борынгы, асылташлар, ышанганнар, көченә, кешеләр.
   3) Укучылар, өчен, кыш көне, җимлек, куйдылар, кошлар, ясап.
   4) Көнне, була, сәгатьтә, кичә, залында, сишәмбе, актлар, унсигез, әдәби.

| **№** | **предложения** | **Макс. кол-во баллов - 8** | **Баллы** |
|---|---|---|---|
| **1.** | **Мәктәпне тәмамлагач, мин табиб булырга телим.** | **2** | |
| **2.** | **Борынгы кешеләр асылташлар көченә ышанганнар.** | **2** | |
| **3.** | **Кыш көне укучылар кошлар өчен җимлек ясап куйдылар.** | **2** | |
| **4.** | **Сишәмбе көнне унсигез сәгатьтә актлар залында кичә була.** | **2** | |

5. **Допиши продолжение предложений** (макс.б. – 10).
1) Авыр булса,  син ... .
2) Дустым белән очрашканчы, мин ... .
3) Дәресләр бетсә  дә ... .
4) Кышкы каникуллар башлану белән,  ... .
5) Сабан туенда иң зур бүләкне ... .

| **№** | **предложения** | **Макс. кол-во баллов - 10** | **Баллы** |
|---|---|---|---|
| 1. | Авыр булса,  **син  ярдәм сора .** | 2 | |
| 2. | Дустым белән очрашканчы, **мин  әни белән киңәштем.** | 2 | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 3. | Дәресләр бетсә дә **өйгә кайтып китмәдек**. | 2 | |
| 4. | Кышкы каникуллар башлану белән, **дәү әниләргә кунакка киттем.** | 2 | |
| 5. | Сабан туенда иң зур бүләкне батырга **бирәләр.** | 2 | |

6. **Напиши эквивалент выражений в татарском языке (макс. б. - 10).**

Приятного чаепития!

Конечно, я верю.

Вы в конкретном случае не правы.

Я Вам бесконечно благодарна!

Примите искренние пожелания.

| **№** | **выражения** | **Макс. кол-во баллов - 10** | **Баллы** |
|---|---|---|---|
| 1. | **Чәйләрегез тәмле булсын!** | 2 | |
| 2. | **Мин ышанам, билгеле.** | 2 | |
| 3. | **Бу очракта сез хаклы түгел (хаксыз).** | 2 | |
| 4. | **Мин сезгә чиксез рәхмәтле!** | 2 | |
| 5. | **Ихлас теләкләремне кабул итегез.** | 2 | |

7. **Найди продолжение пословицы** (макс. б. - 4).

Ахмак дустың булганчы, ... .

1)үзең акыллы бул

2) **акыллы дошманың булсын**

3) дуслар кирәк түгел

8. **Расскрой скобки, поставь глаголы в нужные формы** (по 2 б. = макс.б. – 12).

1) Муса Җәлил биш елга якын гомерен Казанда (уздыр).
2) Дустыңа авырлык (кил), аңа ярдәм (ит) тырыш.
3) Чәчәкләрне иртәнге сәгатьтә (өз) алу мөһим, чөнки алар яхшырак (саклан).

4) Шимбә көнне алар Боз сараена (бар) булалар.

| № | предложения | Макс. кол-во баллов - 12 | Баллы |
|---|---|---|---|
| 1. | Муса Җәлил биш елга якын гомерен Казанда **уздырган.** | 2 | |
| 2. | Дустыңа авырлык **килсә**, аңа ярдәм **итергә** тырыш. | 4 | |
| 3. | Чәчәкләрне иртәнге сәгатьтә **өзеп** алу мөһим, чөнки алар яхшырак **саклана**. | 4 | |
| 4. | Шимбә көнне алар Боз сараена **бармакчы** булалар. | 2 | |

**9.** В какой последовательности необходимо поставить выражения, чтобы получилось предложение? (4 б.)

А) кечкенә инешләр дә
Ә) безнең республикабызны
Б) зур елгалар да
В) бик ямьләндерә

1) **Ә, Б,А,В**
2) Б,А,Ә,В
3) В, Ә, А, Б
4) Ә,В, Б, А

**10.** Составь рассказ из 8-10 предложений по теме “Телләр белгән – илләр гизгән” (макс. -20 б.)

*Телләр белү –зур байлык. Тел белү кешеләргә, төрле милләтләргә аңлашырга, аралашырга ярдәм итә. Без күпмилләтле республикада яшибез. Илебезнең дәүләт теле- рус теле, ә Татарстан Республикасының дәүләт теле – татар теле. Шуңа күрә без рус телен дә татар телен дә яхшы белергә тиешбез. Мин-рус милләтеннән, татар телен үз телэгем белән*

*өйрәнәм. Татар телен белү миңа татар әдәбиятын, мәдәниятен, тарихын белергә аңларга ярдәм итә. Мин бик теләп инглиз телен дә өйрәнәм. Инглиз теле халыкара әһәмияткә ия тел. Чит илләргә чыкканда,  инглиз телен белү бик мөһим. Мәкальдә әйткәнчә, телләр белгән – илләр гизгән.*